КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2024 ел, 28 март г.Казань № 195

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибен раслау турында» 2019 ел, 22 октябрь, 943 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2021 ел, 29 декабрь, 1305 нче; 2023 ел, 11 март, 228 нче; 2023 ел, 27 апрель, 537 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбуланы түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль законның 9 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:»;

әлеге карар белән расланган Билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган гражданнарга социаль түләүләрне гамәлгә ашыру буенча Россия Федерациясенең тапшырылган вәкаләтен гамәлгә ашыру өчен федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына субвенция рәвешендә бирелә торган акчадан файдалану тәртибендә:

1 пунктның икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Тәртип «Россия Федерациясендә халыкны эш белән тәэмин итү турында» 2023 елның 12 декабрендәге 565-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасына тапшырылган Россия Федерациясе вәкаләтләрен (алга таба – тапшырылган вәкаләт) гамәлгә ашырганда кулланыла.»;

4 пунктның дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«ятим балаларга, ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларга, ятим балалар һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балалар арасыннан затларга ай саен бирелә торган өстәмә түләүгә;».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин